МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

05.06.2023 № 146

**Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгы 25.06.2018 № 376 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында Кагыйдәнамәгә үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының локаль актын Русия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры китерү максатында, 2004 ел 27 нче июль № 79-ФЗ «Русия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте турында» Федераль законы һәм 2003 ел 16 нчы гыйнвар № 3-ЗРТ «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы законы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (кадрлар резервына кертү) биләүгә конкурс үткәрү турындагы Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының (алда – Татарстан Республикасы ГТХМ) 25.06.2018 № 376 боерыгы белән расланган (26.02.2020 № 76, 16.03.2021 № 103, 20.03.2023 № 77 Татарстан Республикасы ГТХМ боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Кагыйдәнамәгә, аны яңа (бирелгән) редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Боерыкны Татарстан Республикасы ГТХМ аппаратының структур бүлекчәләре җитәкчеләренә, министр урынбасарларына һәм барлык дәүләт граждан хезмәткәрләренә җиткерергә.

Министр вазыйфаларын башкаручы Т.В. Кәримуллин

25.06.2018 № 376
Татарстан Республикасы
ГТХМ боерыгы белән
расланган
(05.06. 2023 № 146
боерык редакциясендә)

**Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре**
**һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгында Татарстан Республикасы**
**дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә**
**(кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында**
**Кагыйдәнамә**

1. Гомуми кагыйдәнамәләр

1.1. Әлеге Кагыйдәнамә конкурс комиссиясе составын, аның эш срокларын һәм тәртибен, шулай ук Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгында (алга таба – Татарстан Республикасы ГТХМ) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керү) конкурс үткәрү методикасын билгели (алга таба — конкурс).

Конкурс Русия Федерациясе гражданнарының Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә тиң конституцион рөхсәт хакы, шулай да Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең конкурс нигезендә хезмәттәге үсеш хакы белән тәэмин итә.

1.2. Конкурс «Русия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазифаларына керү конкурсы турында» 01.02.2005 № 112 Русия Федерациясе Президенты Указы белән расланган Русия Федерациясе Дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазифаларына керү конкурсы турында кагыйдәнамә, «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтендә кадрлар резервы турында кагыйдәнамәне раслау турында» 14.03.2011 № УП-127 Татарстан Республикасы Президенты Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтендә кадрлар резервы турында кагыйдәнамә, «Русия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазифаларына керү һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына керү конкурсларының бердәм үткәрү методикасын раслау турында» 31.03.2018 № 397 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Русия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазифаларына керү һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына керү конкурсларының бердәм үткәрү методикасы белән билгеләп куелган тәртиптә һәм шартларда үткәрелә.

1.3. Татарстан Республикасы ГТХМ да конкурс үткәрелми:

«җитәкчеләр» һәм «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категорияләрендә гражданлык хезмәте вазифаларының вәкаләтен билгеле вакытка билгеләгәндә;

ашыгыч хезмәт контрактын төзегәндә;

«Русия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында» 27.07.2004 № 79-ФЗ Федераль законының 28 нче мәкалә 2 нче бүлек, 31 нче мәкалә 1 нче бүлек һәм $60^1$ нче мәкаләнең 9 нчы бүлектә язылган очракларда гражданлык хезмәткәрен башка гражданлык хезмәте вазифасына билгеләгәндә;

гражданлык хезмәтендә кадрлар резервына кертелгән гражданлык хезмәткәрен (гражданны) гражданлык хезмәте вазифасына билгеләгәндә.

1.4. Конкурс үткәрелмәскә мөмкин:

вазифалы бурычларны башкару дәүләт сере белән бәйле Татарстан Республикасы ГТХМ боерыгы белән расланган вазифалар исемлеге буенча гражданлык хезмәтенең аерым вазифаларына билгеләгәндә;

министр карары буенча гражданлык хезмәтенең кече вазифаларына туры килә торган гражданлык хезмәте вазифасына билгеләгәндә;

федераль законнарда каралган башка очракларда.

1.5. сәләт һәм һөнәри белемгә туры килә торган Русия Федерациясе гражданнарының гражданлык хезмәтенә тиң рөхсәт, шулай да конкурс нигезендә гражданлык хезмәткәрләренә вазифадагы үсеш хакын тәэмин итәр өчен;

Русия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләп куелган таләпләргә туры килә торган кандидатларның гомуми санынннан вакант гражданлык хезмәте вазифасына күбрәк килешә торган кандидатларны сайлар өчен;

Татарстан Республикасы ГТХМ кадрлар резервын ясар өчен.

1.6. Конкурсларны үткәргәндә чишелә торган мәсьәләләр:

конкурс биремнәре һәм гамәлләре үткәндә бөтен кандидатлар өчен тиң шартларны тәэмин итү;

кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен бәяләү, аларның гражданлык хезмәте вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән башка квалификация таләпләренә туры килүен тикшерү;

кандидатларның өстәмә һөнәри яңадан әзерләү (әгәр гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләрендә мондый таләпләр каралган булса) программаларын үзләштерү нәтиҗәләре буенча алынган профессиональ дәрәҗәләрен, аларның һөнәри белем дәрәҗәләрен, гражданлык хезмәте стажын яки белгечлек, әзерлек юнәлеше (зурайтылган белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре төркемнәре) буенча эшләрен, шулай ук аларның белгечлекләрен, әзерлек юнәлешләрен, квалификацияләрен чагыштыру.

1.7. Конкурс вакант гражданлык хезмәте вазифасы булган структура булекчәсе җитәкчесенең дәлилләнгән язу мөрәҗәгать нигезендә, кадрлар хезмәте белән ризаланып, Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры (алга таба – министр) карары белән игълан ителә (биредәге Кагыйдәнамәнең 1 нче кушымтасы).

1.8. Татарстан Республикасы ГТХМ ның кадрлар резервына керү конкурсы Татарстан Республикасы ГТХМ гражданлык хезмәте белгечләренә мөмкин мохтаҗның һәм Татарстан Республикасы ГТХМ ның булган кадрлар резервының ел саен үткәрелә торган сынау нәтиҗәләре буенча Министрлыкның кадрлар хезмәте белән оештырыла.

Татарстан Республикасы ГТХМ ның кадрлар резервына керү конкурсын Татарстан Республикасы ГТХМ конкурс комиссиясе әлеге кагыйдәнамәдә язылган тәртиптә үткәрә.

## 2. Конкурс комиссиясенең формалашу һәм эш тәртибе

2.1. «Русия Федерациясенең вакант дәүләт гражданлык хезмәте вазифасына керү конкурсы турында» 01.02.2005 № 112 Русия Федерациясе Президенты Указына туры китереп, Татарстан Республикасы ГТХМ да даими эшли торган конкурс комиссиясе корыла. Аның составы Татарстан Республикасы ГТХМ боерыгы белән раслана. Комиссия составына кергән вазифалы шәхесләрнең персональ составы үзгәргәндә Татарстан Республикасы ГТХМ боерыгы белән туры килгән үзгәрешләр языла.

2.2. Конкурс комиссиясе рәистән, рәис урынбасарыннан, секретарьдән һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

2.3. Конкурс комиссиясе рәисе конкурс комиссиясе эшен җитәкләп бара, утырышны үткәрү көнен билгели һәм аның көн тәртибен раслый, конкурс комиссиясе утырышларында рәислек итә һәм туры килгән документларга кул куя. Конкурс комиссиясе рәисе булмаган вакытта аның хокукларын һәм бурычларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясе секретаре конкурс комиссиясе эшен тәэмин итә (теркәү, гаризалар кабул итү, эшләрне ясау, конкурс комиссиясе беркетмәләрен алып бару, конкурс комиссиясе карарларын рәсмиләштерү).

2.4. Татарстан Республикасы ГТХМ конкурс комиссиясе составына министр яки аның вазыйфаларын башкаручы зат һәм (яки) министр вәкаләтле граждан хезмәткәрләре (шул исәптән кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегеннән һәм гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрелә торган бүлекчәдән), Татарстан Республикасы ГТХМ каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук конкурс комиссиясе составына кертелә торган, тиешле өлкәләрдә һәм граждан хезмәткәрләренең һөнәри хезмәт эшчәнлеге төрләрендә, кадрлар технологияләре һәм дәүләт гражданлык хезмәте мәсьәләләре буенча белгечләр булган, бәйсез экспертларның шәхси мәгълүматларын күрсәтмичә җибәрелгән министр соравы буенча Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан чакырыла торган бәйсез экспертлар - фәнни, мәгариф һәм башка оешма вәкилләре керә. Бәйсез экспертның Татарстан Республикасы ГТХМ Конкурс комиссиясендә булу вакыты өч елдан артмаска тиеш.

Конкурс комиссиясе составына кертелә торган Татарстан Республикасы ГТХМ каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре әлеге совет карары белән билгеләнә.

Татарстан Республикасы ГТХМ карамагындагы Иҗтимагый совет вәкилләренең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санынннан бер өлеш дүрттән ким булмаска тиеш.

2.5. Дәүләт серennән торган мәгълүматны куллану белән бәйле вазифа бурычларын башкара торган вакант гражданлык хезмәтенә керү конкурсын

үткәргәндә конкурс комиссиясе составы, дәүләт сере турында Русия Федерациясе законнарының кагыйдәнамәләре исәпкә алынып, ясала.

2.6. Кабул ителә торган конкурс комиссиясе карарларына тәэсир итә торган кызыксыну бәхәсләре килеп чыгу мөмкинлеген булдырмас итеп конкурс комиссиясе составы ясала.

2.7. Конкурс комиссиясе утырышы вакант гражданлык хезмәте вазифасына керер өчен (кадрлар резервына керер өчен) ике кандидаттан ким булмаганда үткәрелә һәм, аның әгъзалары ике өлеш өчтән ким булмаса, хокуклы дип санала. Татарстан Республикасы ГТХМ да гражданлык хезмәте вазифаларына керә торган комиссия әгъзаларыннан гына торган конкурс комиссиясе утырышын үкәрергә рөхсәт ителми.

2.8. Конкурс комиссиясе:

конкурсны үткәрү көнен, урынын, вакытын һәм тәртибен, кандидатларны сынау ысулларын билгели;

вакант дәүләт гражданлык хезмәте вазифасына кермәкче булган гражданнарны (гражданлык хезмәткәрләрен) конкурс үткәрү шартлары турында белдереп тора һәм аларга киңәш бирә;

кандидатлардан килгән сораулар буенча конкурс документларын бирә;

вакант дәүләт гражданлык хезмәте вазифасы кандидатлары биргән документларны тикшергәннән соң конкурсның икенче этабына кертелгән кандидатлар исемлеген раслый;

кандидатларга билгеләп куелган таләпләргә туры килү сынавын үткәрә;

конкурсны нәтиҗәләү, кандидат конкурс җиңүчесе булып чыккан турында карар итә, аны кадрлар резервына кертер өчен тәкъдим итә.

2.9. Конкурс комиссиясе карары кандидат булмаганда кабул ителә һәм аны вакант гражданлык хезмәте вазифасына билгеләү яисә (аның ризалыгыннан) кадрлар резервына кертү яки моны кире кагу нигезе булыр.

2.10. Конкурс комиссиясенең сайлау нәтиҗәләрен конкурс комиссиясе беркетмәсе рәсмиләштерә. Аңа утырышта катнашкан комиссиянең рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм әгъзалары кулы куела. Шул ук вакытта конкурс комиссиясе карарында гражданлык хезмәте вазифасына беренче тапкыр кабул ителгән яисә Татарстан Республикасы ГТХМ да гражданлык хезмәте вазифасының башка төркеменә яисә категориясенә күчергән вакытта гражданин өчен сынап карау дәвамлыгы буенча тәкъдим бирелергә мөмкин.

2.11. Конкурсны турыдан-туры үткәрү буенча оештыруны һәм тәэмин итүне, конкурс комиссиясе эшен Татарстан Республикасы ГТХМ кадрлар хезмәте башкара.

## 3. Конкурс катнашучылары

3.1. 18 яшькә җиткән Русия Федерациясе гражданнарына, Русия Федерациясе дәүләт телен белә торган һәм дәүләт гражданлык хезмәте турында Русия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләп куелган вакант вазифага (кадрлар резервына керүгә) квалификацион таләпләренә туры килә торган гражданнарга конкурста катнашырга рөхсәт ителә.

Гражданлык хезмәткәре, конкурс үткәрү вакытында ул, нинди вазифада булганга карамастан, гомуми нигезләр буенча конкурста катнашырга хаклы.

3.2. Татарстан Республикасы ГТХМ ның гражданлык хезмәте вакант вазифасына керүче (кадрлар резервына керүче) кандидатларның таләпләренә туры килә торган һәм билгеләп куелган вакыт эчендә бөтен кирәк документларны биргән гражданнарга конкурста катнашырга рөхсәт ителә.

3.3. Гражданинга (граждан хезмәткәренә) конкурста катнашырга рөхсәт ителми:

һөнәри белем дәрәҗәсенә, гражданлык хезмәте стажына яки белгечлек буенча эш стажына, әзерлек юнәлешенә квалификация таләпләренә туры килмәү сәбәпле;

аның белгечлеккә квалификация таләпләренә, әзерлек юнәлешенә (белгечлекләрнең һәм әзерлек юнәлешләренең зурайтылган төркемнәренә), профессиональ яңадан әзерләүнең (гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләре белән мондый таләпләр каралган очракта) өстәмә һөнәри программасын үзләштерү нәтиҗәләре буенча алынган квалификациягә туры килмәве сәбәпле;

Русия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте турында законнары белән бәйле һәм гражданлык хезмәтенә керү һәм аны узу белән бәйле чикләүләр булу сәбәпле.

3.4. Вакант дәүләт гражданлык вазифасына кандидатларның квалификацион таләпләре дәүләт гражданлык хезмәте турында федераль һәм республика законнары белән билгеләп куела һәм Татарстан Республикасы ГТХМ боерыгы белән раслана.

3.5. Конкурста катнашырга теләк белдергән Русия Федерациясе гражданины дәүләт Татарстан Республикасы ГТХМ бирә:

а) шәхси гаризаны (биредәге Кагыйдәнамәгә кушымта № 2);

б) Русия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган форма буенча тутырылган һәм имзаланган анкетаны, фотография белән;

в) паспорт яисә аны алмаштыра торган документ күчермәсен (туры килә торган документ конкурска килүгә шәхсән күрсәтелә);

г) кирәкле һөнәри белем, квалификация һәм эш стажын раслый торган документларны:

хезмәт кенәгәсенең тиешенчә расланган күчермәсе (хезмәт (эш) эшчәнлеге беренче тапкыр башкарылган очраклардан тыш) һәм (яки) Русия Федерациясе Хезмәт кодексының 661 статьясы нигезендә билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар;

белем һәм (яки) квалификация турында документлар күчермәләре, шулай ук граждан теләге буенча хезмәт (эш) урыны буенча нотариаль яки кадрлар хезмәте тарафыннан расланган фәнни дәрәҗә, фәнни исем бирү турында документлар күчермәләре;

д) гражданинда гражданлык хезмәтенә керергә яисә аны башкарырга комачаулый торган авыру булмаганы турында документ;

е) «Русия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында» 27.07.2004 № 79-ФЗ Федераль законы, башка федераль законнар, Русия Федерациясе

Президенты указлары һәм Русия Федерациясе Хөкүмәте карарлары белән алдан исәпкә алынган башка документларны.

3.6. Конкурста катнашырга теләк биргән Татарстан Республикасы ГТХМ ның гражданлык хезмәткәре Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министры исеменә гариза бирә.

3.7. Вазифа бурычларын башкару буенча вазифа дәүләт яисә закон саклый торган башка серле мәгълүмат куллануы белән бәйле булса, гражданин (гражданлык хезмәткәре) ризалыгыннан гражданлык хезмәте вазифасына кермәкче булган гражданин (гражданлык хезмәткәре) өчен мондый мәгълүматка рөхсәт бирүне рәсмиләштерү гамәле үткәрелә.

Гражданин яллаучы исеменә китергән мәгълүматларның дөреслеге тикшерелергә тиеш. Электрон рәвештә бирелгән мәгълүматлар Русия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә автоматлаштырылган тикшерүгә дучар ителә.

Гражданлык хезмәткәре китергән мәгълүматларның дөреслеге тикшерелүе вакант гражданлык хезмәте вазифасына керү конкурсында катнашкан вакант гражданлык хезмәте вазифасы гражданлык хезмәте вазифаларының югары төркеменә туры килгән очракта гына башкарыла.

3.8. Әлеге Кагыйдәнамәнең 3.5 һәм 3.6 пунктларында күрсәтелгән документларны алу турында игъланны «Русия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмат системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтына һәм Татарстан Республикасы ГТХМ ның рәсми сайтына кертү көненнән бирле 21 календарь көне эчендә гражданин (гражданлык хезмәткәре) әлеге Кагыйдәнамәнең 3.5 һәм 3.6 пунктларында билгеләнгән документларны үзе, почта буенча җибәрү юлы белән яисә югарыда билгеләнгән мәгълүмат системасын кулланып электрон рәвештә Татарстан Республикасы ГТХМ ның кадрлар хезмәтенә китерә. Документларны электрон рәвештә тапшыру тәртибен Русия Федерациясе Хөкүмәте билгеләп куя.

3.9. Документларны нигезле сәбәпсез вакытында китермәү, аларны тулы күләмдә яисә рәсмиләштерү кагыйдәләрен үтәп китермәү аларны гражданиннан кабул итүне кире кагырга нигез булыр.

Документларны нигезле сәбәп буенча вакытында китермәгәндә, аларны тулы булмаган күләмдә яисә рәсмиләштерү кагыйдәләрен үтәмичә китергәндә министр аларны кабул итү вакытларын күчерергә хаклы.

## 4. Конкурсны үткәрү методикасы

4.1. Конкурсны үткәргән вакытта Русия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен, һөнәри һәм шәхси сыйфатларын сынау ысулларыннан корылган конкурс биремнәре һәм гамәлләре кулланыла.

Конкурс барышында кандидатларның һөнәри дәрәҗәләрен чагыштыру, аларның һөнәри белем дәрәҗәләрен, гражданлык хезмәте стажын яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эшләрен, шулай ук һөнәри яңадан әзерлекнең (гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләре белән мондый таләпләр каралган очракта) өстәмә һөнәри

программаларын үзләштерү нәтиҗәләре буенча алынган белгечлекләрен, әзерлек юнәлешләрен (зурайтылган белгечлек төркемнәре һәм әзерлек юнәлешләре), квалификацияләрен чагыштыру гамәлгә ашырыла.

4.2. Кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен бәяләү әлеге Кагыйдәнамәгә 3 нче кушымта буенча бәяләү ысулларына һәм әлеге Кагыйдәнамәгә 4 нче кушымта буенча бәяләү ысулларын тасвирлауга ярашлы рәвештә гражданлык хезмәтенең вакантлы вазифалары категорияләреннән (кадрлар резервы формалашкан гражданлык хезмәте вазыйфалары төркеме) һәм төркемнәреннән чыгып башкарыла.

4.3. Кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен, һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү критерийлары Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының гражданлык хезмәте вазыйфаларына куелган квалификация таләпләре нигезендә эшләнгән.

Конкурс нинди вазифаларның төркеменә һәм категориясенә үткәрелүгә карап, конкурста катнашучыларны сынау критерийләре һәм сайланган сынау ысуллары үзгәрелергә мөмкин.

4.4. Кандидатларны чагыштыру һәм сайлап алу алар конкурс биремнәрен чишү һәм конкурс гамәлләрен үтү нәтиҗәләре нигезендә башкарыла.

4.5. Конкурс ике этап аша үтә.

4.5.1. Беренче этапта кадрлар хезмәте оештыра:

а) конкурсны үткәрү турында мәгълүматны хәзерләү һәм аны Татарстан Республикасы ГТХМ ның һәм «Русия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итү бердәм мәгълүмат системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтына кертү. Мәгълүмат түбәндәгеләрдән тора:

вакант вазифа (кадрлар резервына керер өчен вазифа) исеме,

гражданлык хезмәте вазифаларының категориясе һәм төркеме,

дәгъвачы шул вазифага керүгә салынган квалификация таләпләре,

гражданлык хезмәтен үтү шартлары,

китерелергә тиеш булган документларны кабул итү урыны һәм вакыты, билгеләнгән документларны кабул итү срогы,

конкурсны үткәрүнең чамалана торган датасы, урыны һәм аның үткәрү тәртибе,

сынау ысуллары турында мәгълүматлар,

гражданлык хезмәткәренең вазифа бурычлары, хаклары һәм вазифа бурычларын башкармау (тиешле башкармау), гражданлык хезмәткәренең һөнәри хезмәтенең нәтиҗәлелеге күрсәткечләре артыннан җаваплылыктан торган вазифа регламентының кагыйдәләре,

кандидат үзенең һөнәри дәрәҗәсен мөстәкыйль рәвештә сынар өчен конкурс чикләреннән тыш алдынгы квалификацион тестны үтү мөмкинлеге турында «Русия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итү бердәм мәгълүмат системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасының сайтында мәгълүмат;

б) гражданин (гражданлык хезмәткәре) китергән документларны тикшерү. Электрон төрдә китерелгән мәгълүматлар Русия Федерациясе Хөкүмәте белән билгеләнгән тәртиптә автоматлаштырылган тикшерү астына куела. Татарстан

Республикасы ГТХМ да шәхси мәгълүматларны эшкәрткәндә шәхси мәгълүматларны аларга хаксыз яисә очраклы рөхсәттән, бетерүдән, үзгәртүдән, юл ябудан, күчермәдән, китерүдән, таратудан, шулай да шәхси мәгълүматлар тарафына башка хаксыз эшләрдән саклар өчен шәхси мәгълүматлар өлкәсендә Русия Федерациясе законнарына туры китереп хокук, оештыру һәм техник чаралары башкарыла яисә аларның башкарылуы тәэмин ителә;

в) гражданның (граждан хезмәткәренең) кирәкле һөнәри дәрәҗәгә туры килүен тикшерү, гражданлык хезмәте вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән башка квалификация таләпләренә.

Конкурсның беренче этабы кабул итү турында белдерү кертелгән көннән башлана һәм 21 көннән иртәрәк түгел тәмамлана.

4.5.2. Конкурсның икенче этабы конкурста катнашыр өчен документларны кабул итү тәмамланудан соң 30 календарь көне үткәнче үткәрелә, ә дәүләт яисә закон саклый торган башка сердән торган мәгълүматка рөхсәтне рәсмиләштергән очракта конкурсның икенче этабын үткәрү срогын министр билгели.

4.6. Гражданинга гражданлык хезмәтенә Русия Федерациясенең федераль законнары һәм башка норматив хокук актларына туры китереп керергә комачаулый торган шартларны тикшергәндә мондый шартлар табылган очракта гражданин язу формада конкурста катнашуны кире кагу сәбәпләре турында министр белән белдерелә. Әгәр гражданин конкурста катнашыр өчен документларны электрон төрдә китерсә, конкурста катнашуны кире кагу сәбәпләре турында белдерү аңа ныгытылган квалификацияле электрон имза куелган һәм дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләти мәгълүмат системасы куллануы белән электрон документ формасында җибәрелә.

4.7. Конкурста катнашырга рөхсәт бирелмәгән вакант гражданлык хезмәте вазифасына керү (кадрлар резервына керү) дәгъвачысы Русия Федерациясе законнарына туры китереп бу карар турында шикаять бирергә хаклы.

4.8. Билгеләп куелган квалификацион таләпләргә туры килә торган кандидатларның саны бер вакант гражданлык хезмәте вазифасына (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазифасына) икедән ким булмау конкурсның беренче этапның тәмамлану шарты булыр. Бу кандидатларны алга таба сайлауны башкарырга мөмкинлек бирә.

Кандидатлар булмаган очракта яисә вазифаның квалификацион таләпләренә туры килә торган бер генә кандидат булган вакытта конкурс булдырылмаган дип танылa. Бу очракта бердән бер кандидат кандидатларның кирәк саны булмаган аркасында конкурс комиссиясе карары буенча конкурс булдырылмаган дип танылганы турында язу рәвешендә белдерелә.

4.9. Билгеләп куелган таләпләргә иң югары дәрәҗәдә туры килә торган һәм конкурста алга таба катнашырга тәкъдим ителгән кандидатлар исемлеге төзелүе турында конкурс комиссиясе рәисе белән раслана торган конкурс комиссиясенең карары беренче этап нәтиҗәсе булыр.

4.10. Конкурсның икенче этабын үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында карарны гражданлык хезмәтенең вакант вазифаларына керү дәгъвалаучылары китергән мәгълүматларның дөреслеген тикшергәннән соң, шулай да дәүләт һәм закон белән башка саклана торган башка сердән торган мәгълүматларга рөхсәт кирәге очрагында рәсмиләштергәннән соң министр кабул итә.

4.11. Кадрлар хезмәте конкурсның икенче этабы башланганына кадәрь 15 көн алдан Татарстан Республикасы ГТХМ ның рәсми сайтына һәм «Русия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмат системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтына икенче этап үткәрүнең датасы, урыны һәм вакыты турында мәгълүматны, конкурста катнашырга рөхсәт бирелгән гражданнар (гражданлык хезмәткәрләр) исемлеген кертә һәм туры килгән хәбәрләрне язу формасында кандидатларга җибәрә, шул ук вакытта конкурста катнашыр өчен документларны электрон төрдә китергән кандидатларга — ныгытылган квалификацияле электрон имза куелган һәм билгеләнгән мәгълүмат системасы куллануы белән электрон документ формасында.

4.12. Шулай да конкурсны оештыру «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәте кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба — Бердәм мәгълүмат кадрлар системасы) кулланып башкарыла.

4.13. Кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен, һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү өчен Конкурс комиссиясе әлеге конкурста кулланылачак конкрет бәяләү ысулларын, аларны куллану чиратлыгын билгели. Һәр конкурс биремен үтәгән өчен куелган минималь балл саны 0 балл дип санала.

Конкурс процедуралары барышында кандидатларны бәяләү өчен әлеге Кагыйдәнамәгә 3 нче кушымтада күрсәтелгән өчтән дә ким булмаган бәяләү ысулы кулланыла. Кандидат белән тест һәм индивидуаль әңгәмә мәҗбүри ысуллар.

4.14. Татарстан Республикасы ГТХМ ның эш юнәлешләре буенча норматив хокук актлары һәм конкурс гамәлләрен үтүгә хәзерләнер өчен гомуми сораулар исемлеге кандидатларга танышыр өчен аларны үткәрүгә кадәрь 3 эш көне үткәнче ачык булырга тиеш.

4.15. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын сынаган вакытта конкурс комиссиясе гражданлык хезмәте вазифасына туры килә торган квалификацион таләпләрдән һәм бу вазифа буенча вазифа регламентының башка кагыйдәләреннән, шулай да дәүләт гражданлык хезмәте турында биредәге Кагыйдәнамә һәм Русия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләп куелган башка кагыйдәләрдән чыгып эш итә.

4.16. Кандидатлар конкурс биремнәрен эшләгәндә контрольне тәэмин итү максатыннан конкурс процедуралары барышында конкурс комиссиясенең вәкилләре булып тора. Кандидатлар конкурс биремнәрен эшләгәндә һәм конкурс комиссиясенең утырышын үткәргәндә министр карары буенча конкурс процедураларын үткәрүнең видео- һәм (яисә) аудиоязуы яисә стенограммасы алып барыла.

4.17. Конкурс комиссиясенең утырышында һәр кандидат белән шәхси әңгәмә үткәрәләр. Аның барышында кандидат башка конкурс биремнәрен эшләү нәтиҗәләре турында сөйләшелә, аның һөнәри дәрәҗәсен билгеләү максатыннан сорау бирелә. Конкурс комиссиясе кандидат белән кара-каршы шәхси әңгәмәне үткәрүсез җиңүчене билгеләү турында конкурс комиссиясенең карарын кабул итүе ярамый. Конкурс комиссиясе утырышны видеоконференция форматында

(техник мөмкинлек булганда) аның әгъзасы яки кандидаты тәкъдиме буенча мондый карарның сәбәбен (Кагыйдәнамәсен) күрсәтеп үткәрү турында Карар кабул итә ала.

Шәхси әңгәмә тәмамлануга комиссиянең һәр әгъзасы кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын сынау нәтиҗәләрен Кагыйдәнамәнең 5 нче кушымтасына карата форма буенча төзелә торган конкурс бюллетененә кертә, кирәк булганда кабул ителгән карарны нигезли торган кыска дәлилне язып.

4.18. Кандидатның йомгак баллы шәхси әңгәмә, башка конкурс биремнәренең нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзалары белән кандидатка куелган һәм тест һәм башка охшаш конкурс процедуралары нәтиҗәләре буенча кандидат белән җыелган балларның урта арифметик суммасы буларак билгеләнә.

Кандидатларның йомгаклау балларын чагыштыру нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе секретаре кандидатларның йомгаклау баллары кими бару тәртибендә рейтингын төзи.

4.19. Әгәр конкурс нәтиҗәсендә гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (кадрлар резервына кертү) биләү өчен кирәкле һөнәри дәрәҗәгә ия булган кандидатлар ачыкланмаса, яллаучы вәкиле кабат конкурс үткәрү турында карар кабул итә ала.

4.20. Гражданлык хезмәтенең вакант вазифасына (кадрлар резервына керү кандидаты (кандидатлары)) конкурсның җиңүчесен билгеләү турында конкурс комиссиясенең карары утырышта булган әгъзаларның ачык сайлау тавышларының гади күбесе белән кабул ителә.

4.21. Ике һәм икедән артык конкурс катнашучылары белән җыелган башка бертигез күрсәткечләр булганда конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч булыр.

4.22. Конкурс комиссиясенең сайлау нәтиҗәләре гражданлык хезмәтенең вакант вазифаларына керү конкурсы нәтиҗәләре буенча 6 нчы кушымтага карата форма буенча һәм кадрлар резервына керү конкурсының нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе утырышының протоколы белән 7 нче кушымтага карата форма буенча конкурс комиссиясе карары белән рәсмиләштерелә.

Билгеләнгән карар (протокол) конкурс комиссиясенең сынау нәтиҗәләре буенча җыелган баллар һәм кандидатларның алган урыннары язылуы белән кандидатлар рейтингыннан тора.

